


**Зәйдулла, Ркаил Ильяс Алкинның соңгы мәхәббәте: роман / Р. Зәйдулла // Казан утлары. – 2020. – № 10 (1176). – Б. 3-51.**

Ркаил Зәйдулла - татар язучысы, шагыйрь, прозаик һәм публицист, Муса Җәлил премиясе, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.

*«Ташкент вокзалында Ильяс Алкинны бер яшь хатын-кыз каршы алды. Егермедән яңарак кына узган булса кирәк. Әле ничә еллар элек кенә андыйларны «сазаган кыз» дип атарлар иде, хәзер әйтеп кара! Әнә нинди ышанычлы адымнар белән каршыга килде, соры күзендә нинди тәвәккәллек! Кызыл косынкасыннан ташып чыккан коңгырт чәче маңгаена төшкән, ул аны ара-тирә кул сырты белән генә уң якка авыштырып куя. Иреннәре тыгыз, елмайганда, тип-тигез ак тешләре эреләнеп җемелдәп китә. Өстендә аксыл зәңгәр блузка, күлмәгенең итәге ботларының тулылыгына игътибар итәрлек чама белән тегелгән. Ильяс, күз-керфеген кытыклаган уйларыннан оялып, карашын читкә алды. Яшь җилкенчәк түгел бит инде ул, ир уртасы кеше, бүген генә иртән чигәсендәге ике бөртек чал чәчне йолкып аткан иде. Уза гомер! Ләкин бит йөрәк... сүрелмәгән әле, Аллага шөкер. Дөрес, елганың үз ярларына кайтып төшеп, камышларга кагылудан да сөенеч эзләгән фасылы хәзер. Ул үзе дә сизмәстән як-ягына карап алды…»*

**Романның дәвамын «Казан утлары» журналының 2020 елның 10нчы санында укый аласыз.**